# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуларын тану хакында

**1 статья.** Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуларын танырга:

«Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1680-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11-12);

«Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1998 елның 22 декабрендәге 1926 номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, №1);

«Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» 1992 елның 22 декабрендәге 1681-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11-12).

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М. Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1143